Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең
Яңгул авылы торак пунктында ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

27 ноябрь 2023 ел № 2

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1.Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең Яңгул авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешенең, түбән керемле (80 яшькә җиткән) ялгыз өлкән яшьтәге пенсионерлардан, онкология авыруларыннан, Россия Армиясендә хезмәт итүчеләрдән, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарны, 2023 елда Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә контракт төзегән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, үзара салым суммасының 90% ы күләмендә ташламалар бирү белән, 2024 елда үзара салым акчасын 1400 сум күләмендә кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Яңгул авылы урамнарын тәртипкә китерү;

- Яңгул авылының Татарстан (мәктәпкә кадәр), Тау асты һәм Тынычлык урамнарына асфальт салу;

- Янгул авылында Муса Җәлил урамында комплектлаштырылган янгынга каршы гидрант сатып алу һәм аны урнаштыру;

- Татарстан урамына асфальт-бетон белән капланган җәяүлеләрөчен тротуар салу;

- Яңгул авылы Дуслык урамында урнашкан зиратның агачларын кисү, чистарту һәм тигезләү;

- Татарстан, Дуслык һәм Муса Җәлил урамнарында видеокүзәтү системасын урнаштыру.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Яңгул авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән Балтач муниципаль районының рәсми сайтында игълан итәргә. baltasi.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru).

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Татарстан Республикасы
Балтач районы
Яңгул авыл җирлеге башлыгы Р. Ф. Габдрахманов